

## СӨЕНЧЕ, УСАКИЧҮГӘ КАРА КАРГАЛАР КАЙТТЫ!

Яңадан тормыш кайный. Каргалар тырышып оя коралар. Тиздән туйлары башланачак. Бу исә җәй үзен озак көттермәячәк дигән сүз. Усакичүнең чишмә башындагы һә м мәчет - гәйнә очы урамнары почмагындагы безнең күз өйрәнгән карга оялый торган карт өянкеләр хәтсездән юк, ләкин хәтердән юылмый гына түгел, искә төшеп, күпне хәтерләтеп, күңелне чемердәтеп куя. Усакичү язларының күренеше В.К.Саврасовның "каргалар кайтты" картинасыннан болайрак. Күңелсез, ачлы-туклы борынгы урыс авылы тормышын тасвирлаучы картинадан аермалы буларак, безнең хәтердә уелып калган язгы усакичү "сүрәте" табигать уянуын, өмет, яшәү дәртен чагылдыра. Күрегез, каргалар ыгы-зыгылары белән кешеләрне хәтерләтмиләрмени? Көлерсең дә, үлерсең дә кыйланышларыннан. Шул балачакта хәтердә уелып калганнары искә төшереп йөргән җирдән шушы көлкесе – чыны бергә "тормыш " дигән шигырь килеп туды. Аны әйбәт тыңласалар да, аптырыйм, бик көлеп бармыйлар никтер. Ләкин сөенеч алганда әйтергә теләгәнем менә нәрсә: киләсе җәйнең рәхәтен күрергә язсын! Каргалар чыркылдашса, чыркылдашсын, үзләренә ошагач, ә без сайрашып яшик,. алар алып кайткан җәйләргә сөенеп, иншаллаһ!

Гөмернең агышларында
җәйләр килә дә, китә
кадерле мизгел булганга
җәйләр бигрәк тиз үтә...